Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының өченче чакырылыш

КАРАР

28.08.2017 ел №62

«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү" хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " гы Федераль закон нигезендә (соңгы үзгәрешләр белән), «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының аерым нигезләмәләренә Әтнә районы прокуратурасының 2017 елның 29 маендагы 02.08.02-17 номерлы протестын карап һәм тикшереп фикер алышканнан соң, Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәве узганнан соң, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының
2017 елның 28 августындагы 62 номерлы
карарына кушымта

**1. Уставның 6 нчы статьясындагы 1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:**
“13) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» гы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;”

**2. 19 нчы статьяның 3 нче пунктындагы 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:**
“1) Җирлек уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, җирлек уставына шушы уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш Россия Федерациясе Конституциясенең федераль законнарның, конституциянең (уставның) яисә Татарстан Республикасы законнарының нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелә;”

**3. 28 нче статьяның 2.3 пунктының 2 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:**
“2) җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш,эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасы идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре идарәсендә, сәяси партия катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш), федераль законнарда каралган очраклардан тыш, һәм оешма идарәсендә катнашу;»

**4. 28 нче статьяны 2.7 - 2.9 пунктлары белән тулыландырырга:**
“2.7. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары буенча уздырыла.

2.8. 2.7 пункты нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында”гы Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасы Президенты депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты

вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән җирле үзидарә органына тиешле карарны кабул итәргә яисә судка мөрәҗәгать итә.

2.9. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштырыла һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә торган тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен бирелә.”

**5. 38 нче статьяга 8 нче пунктны түбәндәге редакциядә өстәргә:**
“8 Җирлек Советының җирлек депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карары вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча, ә әлеге нигез җирлек Советы сессияләре арасында барлыкка килгән очракта, - мондый нигез барлыкка килгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

Татарстан Республикасы Президенты депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн буларак, әлеге гариза җирлек Советына кергән көн санала.

**6. Уставның 41 нче статьясындагы 2 нче пунктын үз көчен югалткан дип танырга.**

**7. 41 нче статьяның 5 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә**:
“5 Муниципаль берәмлек башлыгы «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.».

**8. Уставның 41 нче статьясындагы 4 нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
“4 Җирлек башлыгы җирлек советына үз эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында еллык хисапларны тапшыра, ә җирлек башлыгы җирле администрацияне җитәкләгән очракта, җирле администрация һәм аның карамагындагы башка җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән җирлек Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү турында, хисап бирә.”

**9. 43 нче статьяның 1 нче пунктындагы 16 нчы пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:**
16) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм

кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү”;

**10. 43 нче статьяның 2 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**
“2 Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган йә суд карары буенча процессуаль мәҗбүри итү чараларын кулланган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча сак астына алу яки вазифадан вакытлыча читләштерү рәвешендәге процессуаль мәҗбүри чаралар кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча җирлек уставы нигезендә җирлекнең вазыйфаи заты яисә җирлекнең вәкиллекле органы депутаты башкара.”

**11. 44 нче статьяның 2 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**
“2. Җирлек башкарма комитетының рәсми исеме – Татарстан Республикасының Әтнә Муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты.
Кыскартылган исеме - Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты.”

**12. 46 нчы статьяның 7 нче пунктчасына түбәндәге абзац өстәргә:**
- "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра;

**13. 56 нчы статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:**
“1.1. Авыл җирлеге башлыгының дәүләт алдында җаваплылыгы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 74 статьясы нигезендә башкарыла.”

**14. 57.1 нче статьяның 9 нчы пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**
“9. Әгәр җирлек уставы нигезендә җирлек башлыгы җирлекнең вәкиллекле органы составына керә һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкара икән ,җирлек башлыгын отставкага җибәрү турындагы карар җирлекнең вәкиллекле органы утырышында рәислек итүче депутат тарафыннан имзалана.

**15. 57.1 нче статьяның 10 нчы пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**
«10 Әгәр җирлек советы составына керүче һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкаручы җирлек башлыгы җирлек Советы утырышында катнашса, анда аны отставкага җибәрү мәсьәләсе каралса, әлеге утырыш җирлек Советы депутаты , җирлек Советы тарафыннан моңа вәкаләтле вәкил рәислегендә уза.»

**16. Уставның 76 нчы статьясындагы 4 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**
“Авыл җирлеге Советы мөрәҗәгате буенча авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапның тышкы тикшерүе муниципаль районның контроль-хисап органы тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин”.

**17. 78 нче статьяның 3 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**
“3. Җирлек уставы проекты, җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, җирлек уставын кабул итү, җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәсьәләне караганчы 30 көннән дә соңга калмыйча җирлек Уставына үзгәрешләр һәм

өстәмәләр кертү турындагы муниципаль норматив хокукый акт проекты «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Әтнә таңы» газетасы редакциясе басмаханәсендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш яисә Әтнә муниципаль районының atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru ) авыл җирлеге территорясендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш, бер үк вакытта җирлек Советы тарафыннан билгеләнгән Устав проекты, күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашу тәртибен җирлек Советы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән. Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук җирлек уставына әлеге уставны әлеге норматив актларга туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтү формасында үзгәрешләр кертелгән очракта, гражданнарның аның фикер алышуында катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.»

**18. 79 нчы статьяның 3 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**
«Җирлек уставы, җирлек Советының Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карары күпчелек тарафыннан җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән ике өлештә кабул ителә. Әгәр җирлек башлыгы җирлек органы рәисе вәкаләтләрен башкарса, җирлек башлыгы тавышы җирлек уставын, муниципаль хокукый актны кабул иткәндә җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»

**19. 80 нче статьяның 1 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**
«1. Җирлек уставы, җирлек Советының әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карары, алар кабул ителгәннән соң, җирлек башлыгы тарафыннан федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына җибәрелә. Җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек уставын, муниципаль хокукый актны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булырга мөмкин:
1) уставның, муниципаль хокукый актның Россия Федерациясе Конституциясе уставына, алар нигезендә кабул ителә торган конституцияләргә (уставларга) һәм Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында каршылыгы;
2) уставны, уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны кабул итүнең әлеге Федераль закон белән билгеләнгән тәртибен бозу;
3) Уставта, уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый актта коррупциоген факторлар булу.
1.1. Җирлек уставын, җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту, шулай ук җирлек уставының дәүләт теркәвенең билгеләнгән сроклары бозылганда, гражданнар һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.»

**20. 80 нче статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 нче пункт өстәргә:**

“4. Җирлек уставын федераль закон, Татарстан Республикасы законы белән тәңгәлләштерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Федераль законда, Татарстан Республикасы законында күрсәтелгән срок билгеләнмәгән очракта, җирлек уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү чоры тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы законы үз көченә керү датасын, җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектын гавами тыңлауларда рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм фикер алышу кирәклеген, аның буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу, җирлек вәкиллекле органы утырышларының чиратлылыгын, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәве һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артмаска тиеш.»